РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ САБИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

САБА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ | КАРАР

02.12.2019 | № 1627-п

Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының гомуми белем бирү оешмалары укучыларын балалар илтү өчен махсус билгеләнгән автобуслар белән йөртүне оештыру буенча муниципаль хезмәт күрсәтү бәясен исәпләү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында

“Россия Федерациясендә мәгариф турында”гы 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль закон һәм “Гомуми белем бирү оешмалары укучыларын балалар илтү өчен махсус билгеләнгән автобуслар белән йөртүне оештыруны финанслау нормативларын исәпләү буенча методик тәкъдимнәрне раслау турында”гы 2010 елның 5 июлендәге 545 номерлы ТР Министрлар Кабинеты карары нигезендә, Саба муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының гомуми белем бирү оешмалары укучыларын балалар илтү өчен махсус билгеләнгән автобуслар белән йөртүне оештыру буенча муниципаль хезмәт күрсәтү бәясен исәпләү тәртибе турындагы нигезләмәне расларга (кушымта итеп бирелә).

2. Әлеге карарны Интернет челтәрендә - Татарстан Республикасының Хокукый мәгълүматлар турындагы http://pravo.tatarstan.ru рәсми порталында һәм Саба муниципаль районының http://saby.tatarstan.ru рәсми сайтында бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Башкарма комитет җитәкчесенең икътисад буенча урынбасары – икътисад бүлеге башлыгы М. М. Баһмановка йөкләргә.

Саба муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе М.Р.Ишниязов

Татарстан Республикасы
Саба муниципаль районы
Башкарма комитетының
2019 елның 2 декабрендәге
1627-п номерлы карары белән
РАСЛАНГАН

**Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының гомуми белем бирү оешмалары укучыларын балалар илтү өчен махсус билгеләнгән автобуслар белән йөртүне оештыру буенча муниципаль хезмәт күрсәтү бәясен исәпләү тәртибе турында Нигезләмә**

1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге Нигезләмә Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының гомуми белем бирү оешмалары укучыларын балалар илтү өчен махсус билгеләнгән автобуслар белән йөртүне оештыру буенча муниципаль хезмәт күрсәтү бәясен исәпләү механизмын билгели (алга таба - муниципаль хезмәт).

1.2. Муниципаль хезмәт күрсәтү бәясе муниципаль хезмәт күрсәтү бәясе нормативы, автотранспорт чаралары саны һәм хисап чорына автотранспорт чараларының факттагы узган юлы нигезендә исәпләнә.

1.3. Муниципаль хезмәт күрсәтү бәясе нормативлары ел саен Саба муниципаль районы Башкарма комитеты тарафыннан раслана.

1.4. Муниципаль хезмәт күрсәтү бәясен формалаштырганда автотранспорт чараларының факттагы узган юлы турындагы мәгълүмат, автотранспорт чарасының расланган паспорты кысаларында башкарылган хисап елы өчен автотранспорт чарасының факттагы узган юлы буларак, Татарстан Республикасында автотранспорт чараларының аерым төрләрен мониторинглауның бердәм системасы мәгълүматлары буенча кабул ителә.

2. Муниципаль хезмәт күрсәтү бәясен исәпләү

2.1. I - муниципаль берәмлегенең муниципаль хезмәт күрсәтү бәясе түбәндәге формула буенча исәпләп чыгарыла:

$$S_i = \sum_{m=1}^{k} (n_{f\,m} \times NF_{km_m} + NF_{as\,m} \times M_m),$$

монда:

$S_i$ – муниципаль хезмәт күрсәтү бәясе;

$n_{fm}$ - m модельле автотранспорт чараларының факттагы узган юлы, километр;

$NF_{km_m}$- гомуми белем бирү оешмалары укучыларын балалар илтү өчен махсус билгеләнгән автобуслар белән йөртүне оештыру бәясе нормативының бер километрга ставкасы,сум;

$NF_{asm}$- гомуми белем бирү оешмалары укучыларын балалар илтү өчен махсус билгеләнгән автобуслар белән йөртүне оештыру бәясе нормативының бер автотранспорт чарасына ставкасы, сум;

$M_m$- m модельле автотранспорт чаралары саны, берәмлек;

m- муниципаль берәмлектә кулланыла торган автобус моделе исеме;

k- муниципаль берәмлектә кулланыла торган автобус модельләре саны.